САК-СОК

ТАТАР
ХАЛЫҚ
БӘЕТЕ



ТАТАР
ХАЛЫҠ
БӘЕТЕ

САК-СОК

Рәссамы
ТАВИЛ
ХАҖИӘХМӘТОВ

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
Казан 1991

Мәдрәсәләрдә китап киштәсе,
Сак белән Сокның бәетен иштәсе.

Мәдрәсәләрдә пыяла ишек,
Сак белән Сокның бәетен ишет.

Әнкәй орышты тимер ук өчен,
Әнкәй орышты бигрәк юк өчен.

Җимнәр ташыйдыр кошлар басудан,
Әнкәй каргады безне ачудан.

Самовар куйды, чәйләр эчерде,
Эчеп бетергәч, каргап очырды.

Яңа туннымны ботак ертҡандыр,
Гомрем беткәнгә, нәфсем тартҡандыр.

Әткәй калдырды, өйдә торсын, дип.
Әнкәй каргады, Сак-Сок булсын, дип.

Қыйбла ягыннан җилләр исәдер,
Безнең ризыкны әнкәй кисәдер.

Бардык урманга, җыйдык карлыган,
Без ятимнәрне әнкәй каргаган.

Төшкәндер безгә әнкәй каргышы,
Үзебез туганчы тәкъдир язмышы.

Әнкәй каргагач, Сак-Сок булдык без,
Бу дөньялардан гыйбрәт алдык без.

Су буйларында бик күп йөрдек без.
Сак-Сок булгачтын, дөнья гиздек без.

Чыктык басуга, урак урырга,
Ходай язгандыр шулай булырга.

Қистем пар нарат яңа ызбага,
Ике күземнән канлы яшь ага.

Су буйларында бала үрдәкләр,
Искә төшкәндә өзелә үзәкләр.

Аклы күлмәкне туя кимәдем,
Газиз әнкәмне туя күрмәдем.

Бер ел тулганчы кайтам, дип йөрдем,
Бер ел тулгачтын, өметне өздем.

Урныбыз урман, икебез туган,
Кавышу юк безгә, әнкәй каргаган.

Өйгән кибәнне җилләр тарата,
Кавышабыз дигәч, хәзер таң ата.

Кояш чыкканда кан тула күзгә,
Кыямәт көнсез кавышу юк безгә.

Бардым урманга, кистем пар каен,
Газиз әнкәмне сагынам көн саен.

Мамык эшләпә алып кайтыгыз,
Әнкәйне күргәч, сәлам әйтегез.

Яңгыр явадыр, әнкәй, башыма,
Елап килдек без әнкәй каршына.

Әнкәй елыйдыр, ник каргадым, дип,
Сак-Сок йөридер, харап булдык, дип.

Бардым урманга, җиләкләр пешкәч,
Әнкәй елыйдыр, исенә төшкәч.

Кара карлыгач, сары сандугач,
Әнкәй, елама, үзең каргагач.

Болай булдык без: каргыш тәдбире[1].
Елама, әнкәй,— ходай тәкъдире.

Калган киемне алып куярсың,
Исеңә төшкәч, алып иснәрсең.

---

[1] *Тәдбир* — эшнең ахырын уйлап эшләү, алдан күрү.

Бик күп еласаң, китапка кара,
Безне сагынсаң, Сак-Сокка кара.

Қитап укырсың, гыйбрәт алырсың,
Қошлар үткәндә карап калырсың.

Имезгән сөткә, әнкәй, өрсәнә[1],
Қыямәт көндә бәхил булсана.

Газиз әнкәем, бер сүз әйтәем,
Бәхиллек бирсәң, өйгә кайтаем.

---

[1] Вариантларда бу сүз урынында «белсәнә», «сусама», «су салма» кебек сүзләр дә китерелә. Биредә сөтен имезгән ана каргышы кире кайтмый дигән борынгы ышанулар чагылыш тапкан.

Мамык эшләпәм җилгә очырдым,
Ике баламны каргап очырдым.

Мендем ботакка, карадым як-якка,
Ике баламны каргадым юкка.

Җәйгән җәймәмнең калды яртысы,
Ике баламның калмады берсе.

Моңлы моңлансын, зарлы саргайсын,
Балаң очырдың, кемгә еларсың.

Мәдрәсә-мәсҗед, пыяла ишек,
Сак белән Сокның бәетен ишет.

Төшкәндер безгә әнкәй каргышы,
Анадин тугач, тәкъдир язмышы.

Идел буенда диңгез камышы,
Кара урманда Сак-Сок тавышы.

Сары күлмәгем һич тә кимәдем,
Өйдән чыкканда, сау бул, димәдем.



Җәй көннәрендә сайрый сандугач,
Әнкәй, елама, үзең каргагач.

Якты дөньяны күрми калабыз,
Каргады безне газиз анабыз.

Әткәй калдыргач, өйдә калдык без,
Әнкәй каргагач, Сак-Сок булдык без.

Йокыга киткәч, бер төш күрдек без,
Җәй көннәрендә ялгыз йөрдек без.

Су буйларында балалы үрдәк,
Исемә төшкәч, өзеләдер үзәк.

Алты яшьләрдә бергә йөрдек без,
Җиде яшьләрдә Сак-Сок булдык без.

Ишегалдында җиктем пар карат,
Әнкәй каргагач, яралды канат.

Бардым урманга, сайрый сандугач,
Һушларым китте эзләп булмагач.

Күз яшьләремнең калды яртысы,
Ике баламның калмады берсе.

Әнкәй, токмачны үзең күп иттең,
Әткәй кайтканчы, безне юк иттең.

Әткәмез калды безнең мәчеттә,
Без тилмерәбез икебез читтә.

Яшел путамны урый белмәдем,
Өйдән чыкканда, сау бул, димәдем.

Әнкәй, кер юдың суның буенда.
Сак-Сок булыр дип юктыр уеңда.

Бардым урманга, бастым баланга,
Балам кычкыра кара урманда.

Ишегалдымда имән дугасы,
Әткәй, елама — әнкәй догасы.

Элекке көнне икәү уйнадык,
Әнкәй каргар дип, без уйламадык.

Әнкәй каргады, әткәй, белдеңме?!
Турыңнан очтык, әткәй, күрдеңме?!

30 тиен.

Кече яшьтәге мәктәп балаларына

САК-СОК

татарское народное сказание

(на татарском языке)

ИБ № 5720

Редакторы **И. Зөлкарнәева,** художество редакторы **Ф. Хәсьянова,** техник редакторы **Р. Ильясова,** корректоры **С. Мифтахова.** Җыярга тапшырылды 29.03.90. Басарга кул куелды 17.12.90. Формат 60×90[1]/8. Офсет кәгазе № 1. «Литературная» гарнитурасы. Кабарынкы басма. Шартлы басма табагы 2,0. Шартлы буяу-оттиск 10,0. Нәшер-хисап табагы 2,87. Тиражы 200 000 экз. Заказ Д-170. Бәясе 30 тиен.

Татарстан китап нәшрияты, 420111, Казан, Бауман ур., 19. КПССның Татарстан республика комитеты нәшрияты типографиясе, 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

ББК 82/2Р-ТАТ/-3
с. 17.

С $\frac{4803560204-290}{М\ 132\ (03)-91}$ 201—90

ISBN 5—298—00500—4

© Татарстан китап нәшрияты, 1990
© Тавил Хаҗиәхмәтов рәсемнәре, 1990